КИЛЕШЕНГӘН:
балалар белән эш буенча
директор урынбасары
__________Р. Н. Каюмова
«_21_» сентябрь 2020 ел

РАСЛЫЙ:
«ҮКС» МБУ директоры
вазифаларын башкаручы
____________Г.Д.Юстус
«_21_» сентябрь 2020 ел

**«Әти, әни, мин – китап укучы гаилә» шәһәркүләм фотобәйгесенең**

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1 Бу нигезләмә «Әти, әни, мин – китап укучы гаилә» (алга таба – Бәйге) шәһәркүләм фотобәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2 Бәйгенең оештыручысы - «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесы.

## 2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары

2.1 Бәйгенең төп максаты – яшь буында татар теленә һәм китап укуга кызыксыну уяту.

2.2 Бәйгенең бурычлары:

- татар әдәбиятына игътибарны көчәйтү;
- гаилә белән китап уку традицияләрен торгызу;
- китапханәләрдә китап укучы балалар һәм яшьләр санын арттыру.

## 3. Бәйгедә катнашучылар

3.1 Бәйгедә 3 - 15 яшьтәге теләге булган һәркем катнаша ала.

3.2 Бәйге түбәндәге яшь төркемнәрендә үткәрелә:

- 3-4 яшьтәге балалар;
- 5-6 яшьтәге балалар;
- 7-11 яшьтәге балалар;
- 12-15 яшьтәге балалар.

## 4. Бәйгенең шартлары

4.1 Бәйгедә катнашучылар 2020 елның 21 нче сентябреннән 2020 елның 11 нче октябренә кадәр 12нче санлы китапханәнең электрон почтасына үзләренең фотографияләрен юллый: cbs_filial12@mail.ru

4.2 Бәйгедә катнашу түләүсез.

4.3 Бәйгедә катнашу Бәйге шартлары белән килешүне аңлата.

## 5. Бәйгене уздыру срогы һәм этаплары

5.1. Бәйге 2020 елның 21 нче сентябреннән 2020 елның 17 нче октябренә кадәр 3 этапта уздырыла:

5.2.1 нче этап: 21.09.2020 - 10.10.2020 – эшләрне кабул итү;

5.3. 2 нче этап: 12.10.2020 - 14.10.2020 – нәтиҗәләр ясау;

5.4. 3 нче этап: 15.10.2020 - 17.10.2020 – Дипломнар тарату.

## 6. Бәйгегә җибәрелүче эшләргә таләпләр

6.1.Бәйгегә китап укучының гаилә белән бер яки берничә китап тотып төшкән фотографиясе кабул ителә.

6.2. Китаплар татар телендә булырга тиеш.

6.3. Фотография jpeg форматында булырга тиеш.

6.4. Фотода кысалар, язулар булырга тиеш түгел.

6.5. Бәйгедә катнашучылар үзләренең бәйгегә җибәрелгән фотографияләренә авторлык хокукларын гарантияли.

## 7. Эшләрне бәяләү критерийлары

7.1 Бәйге эшләрен бәяләү 5-баллы система буенча уздырыла. Йомгаклау нәтиҗәсе балларны кушу юлы белән ирешелә.

7.2 Бәйге эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

- күрсәтелгән темага туры килү;
- оригинальлек һәм мөстәкыйльлек;
- эшне башкаруга иҗади якын килү.

## 8. Жюри әгъзалары

8.1 Эшләрне бәяләүне Бәйгенең жюри әгъзалары гамәлгә ашыра.

8.2 Бәйгене жюри рәисе җитәкли.

8.3. Жюриның барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8.4 Эшләр карау вакытында жюри номинацияләр тәкъдим итә ала.

## 9. Бәйгегә йомгак ясау һәм бүләкләү

9.1 Бәйгедә җиңүчеләрне жюри билгели. Жюри карары ахыргы булып тора һәм яңадан каралмый.

9.2 Җиңүчеләр һәр яшь төркемендә 1, 2, 3 урыннар өчен Дипломнар белән бүләкләнә. Призлы урыннарга кермәгән катнашучылар «Катнашкан өчен» Дипломнары алачак. Дипломнар электрон рәвештә теркәлү карточкасында күрсәтелгән адреска җибәрелә.

## 10. Бәйгене рекламау

Бәйге массакүләм мәгълүмат чараларында, китапханә-челны.рф китапханә сайтында һәм «12нче санлы китапханә» ВКонтакте төркеме битендә: https://vk.com/club137987058 яктыртылачак.

## 11. Бәйгене уздыру урыны һәм элемтәләр өчен телефон

Яр Чаллы үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы филиалы: Яр Чаллы шәһәре, Ш. Усманова урамы, 48 йорт (Яңа шәһәр, 14/01). Телефон: 35-33-86; e-mail: cbs_filial12@mail.ru

Җаваплы: Аксуева А.З.

**Кушымта 1**

**Теркәлү карточкасы:**

«**Әти, әни, мин – китап укучы гаилә**» шәһәркүләм бәйгесенең теркәлү карточкасы:

Катнашучының исем, фамилиясе_______________________________________________

Катнашучының яше (тулы яше) _______________________________________________

Катнашучының балалар бакчасы, укыган мәктәбе_______________________________

Бәйгедә катнашучының телефоны, электрон адресы (телефон, e-mail) ________________

Җитәкчесенең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, телефоны, электрон адресы (телефон, e-mail) ____________________________________________________________________

Бәйге шартлары белән таныштым һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза:

Дата ____________________

Имза ____________________